# КАРАР

**« 06 » апрель 2024 ел  N 3**

**Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Урта Курса авыл җирлегенең Урта Курса авылында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында 2023 елның 28 ноябрендәге 4 номерлы карарга үзгәрешләр кертү мәсьәләсе буенча Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Урта Курса авыл җирлегенең Урта Курса авылында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1,56 статьясы, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, һәм Татарстан Республикасы Арча муниципаль Урта Курса авыл җирлеге Уставының 25 статьясы нигезендә 2024 елның 06 апрелендә Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Урта Курса авыл җирлегенең Урта Курса авылында «Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Урта Курса авыл җирлегенең Урта Курса авылында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында» 2023 елның 28 ноябрендәге 4 номерлы карарына үзгәрешләр кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыены мәсьәләсен яңа редакциядә бәян итү өлешендә гражданнар җыены беркетмәсе төзелде:

«Сез 2024 елда яшәү урыны буенча Арча муниципаль районы Урта Курса авыл җирлеге Урта Курса авылы территориясендә теркәлгән балигъ булган һәр кешегә, түләү күләме 800 сум, көндезге формада укучы студентлардан, 80 яшьтән узган гражданнардан, тумыштан инвалид булганнардан 400 сум күләмендә үзара салым кертү, шулай ук махсус хәрби операциядә катнашучыларны һәм аларның гаилә әгъзаларын (бергә яшәүче ата-аналарын, хатынын, балигъ булган балаларын) түләүдән азат итү һәм җыйналган акчаның түбәндәге җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә тотылуына сез ризамы:

- торак пункт территориясен төзекләндерү (Тукай урамындагы 9 һәм 13 нче йортлар арасындагы территорияне төзекләндерү; балалар мәйданчыгын агымдагы ремонтлау);
- гадәти күмү урыннарын коймалап алу, ремонтлау, төзекләндерү (бензин генераторын сатып алу);
- торак пункт чикләрендә җирле әһәмияттәге гомуми файдаланудагы автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту (юл-урам челтәренең юл япмасын чокырлы ремонтлау)?

Аерым мәсьәләләр буенча экономия булганда, авыл җирлеге башкарма комитетына акчаларны җыенда каралган башка мәсьәләләрне хәл итүгә тотарга.

«ӘЙЕ» «КАРШЫ»

Халык җыены беркетмәсе нигезендә сайлау хокукына ия булган җыенда

катнашучылар исемлегенә 140 кеше кертелгән, жыенда катнашучылар саны 74 кеше.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча халык җыенында катнашучылар тавышы түбәндәгечә бүленде:

"Әйе" позициясе өчен халык җыенында катнашкан 69 кеше тавыш бирде; “Каршы" позициясе өчен җыенда катнашкан 5 кеше тавыш бирде.

Бәян ителгәннәрдән чыгып, халык җыены карар итте:

1. Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Урта Курса авыл җирлегендә Урта Курса авылында халык җыенын булып узган дип танырга, халык җыены нәтиҗәләре дөрес.

« Сез 2024 елда яшәү урыны буенча Арча муниципаль районы Урта Курса авыл җирлеге Урта Курса авылы территориясендә теркәлгән балигъ булган һәр кешегә, түләү күләме 800 сум, көндезге формада укучы студентлардан, 80 яшьтән узган гражданнардан, тумыштан инвалид булганнардан 400 сум күләмендә үзара салым кертү, шулай ук махсус хәрби операциядә катнашучыларны һәм аларның гаилә әгъзаларын (бергә яшәүче ата-аналарын, хатынын, балигъ булган балаларын) түләүдән азат итү һәм җыйналган акчаның түбәндәге җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә тотылуына сез ризамы:

- торак пункт территориясен төзекләндерү (Тукай урамындагы 9 һәм 13 нче йортлар арасындагы территорияне төзекләндерү; балалар мәйданчыгын агымдагы ремонтлау);

- гадәти күмү урыннарын коймалап алу, ремонтлау, төзекләндерү (бензин генераторын сатып алу);

- торак пункт чикләрендә җирле әһәмияттәге гомуми файдаланудагы автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту (юл-урам челтәренең юл япмасын чокырлы ремонтлау)?

Аерым мәсьәләләр буенча экономия булганда, авыл җирлеге башкарма комитетына акчаларны җыенда каралган башка мәсьәләләрне хәл итүгә тотарга кабул ителгән».

3. Әлеге карарны халык күп җыела торган урыннарда мәгълүмат стендларында ТР, Арча районы, Урта Курса авылы, Тукай урамы, 21 йорт йорт адресы буенча интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Арча муниципаль районының рәсми сайтында http://arsk.tatarstan.ru веб-адресы буенча урнаштыру юлы белән игълан итәргә һәм Татарстан Республикасы Рәсми хокукый мәгълүмат порталында http://pravo.tatarstan.ru. веб-адресы буенча бастырып чыгарырга.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары Регистрына кертү өчен җибәрергә.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Урта Курса авыл җирлеге башлыгы
Арча муниципаль районы Вафина Р. Р.